Республика Татарстан
Исполнительный комитет Пестречинского сельского поселения Пестречинского муниципального района
422770, с. Пестрецы,
ул. Советская, 18
Тел.: 8(84367) 3-01-91, 3-01-92.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты
422770, Питрәч авылы,
Совет урамы, 18
Тел.: 8(84367) 3-01-91, 3-01-92.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
«29» ноябрь, 2021 ел № 35

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең Питрәч авылында яңа урамга исем бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» карары, «Дәүләт адреслар реестрында урнаштырыла торган адреслар турында белешмәләр составы, дәүләт адреслар реестрын алып барганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 22 маендагы 492 номерлы карары, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2015 елның 05 ноябрендәге 171н номерлы «Планировка структурасының элементлары, урам-юл челтәре элементлары, адреслау объектлары, биналар (корылмалар) типлары элементлары, адрес реквизитлары сыйфатында кулланыла торган биналарның (корылмаларның) элементлары исемлеген һәм адреслы барлыкка китерүче элементларның кыскартылган исемнәрен раслау турында» боерыгы белән Дәүләт адреслы реестрын актуальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең Питрәч авылында урнашкан урам-юл челтәренең яңа

элементына **«улица Салихзяна Калимуллина»** - **«Салихҗан Кәлимуллин урамы»** исемен 1 нче кушымта нигезендә бирү.

1. Присвоить новому элементу улично-дорожной сети, расположенному в селе Пестрецы Пестречинского сельского поселения Пестречинского муниципального района Республики Татарстан наименование **«улица Салихзяна Калимуллина» - «Салихҗан Калимуллин урамы»** в соответствии с картой-схемой согласно Приложению №1.

2. Дәүләт адреслар реестрында урам-юл челтәре элементының исеме турында белешмәләр урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы П.В. Сиваев

Питрәч авыл җирлеге башкарма
комитетының 2021 елның 29
ноябрендәге 35 нче карары
1 нче кушымта

**Карта – схема**

